## 13. Бер генә

Җир шары шундый зур -
Меңләгән елгалар.
Тик бездә иң матур
Инешләр агалар.
Туган җир сугара -
Иң татлы чишмәләр.
Иң гүзәл чәчкәләр
Тик бездә үсәләр.
Кушымта: Һәркемгә туган як
Бер генә, бер генә.
Син туган җиреңнең
Кадерен бел генә!
Дөньяда кошлар күп,
Җырлары танышлар.
Тик туган ягыңда
Кадерле тавышлар.
Туган як һавасы -
Татлы бал ягылган.
Иң якты йолдызлар
Биредә кабынган.